ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлегенең Янга-Болгар авылында
гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Матюшино авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда үзара салым кертүгә карата 300 сум күләмендә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллау белән килешерме? - Яңа-Болгар авылында чишмәне төзекләндерү” дигән сорау буенча 2019 елның 16 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 55 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 35 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 35 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Яңа-Болгар авылында гражданнар җыены узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. «2020 елда авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән гражданнарның ташламалы категориясеннән тыш, Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Янга-Болгар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллау белән килешерме?: - Яңа-Болгар авылында чишмәне төзекләндерү, дигән сорау буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Яңа Болгар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына юллау өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Ш.Р. Азизов